РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
СТАРОКАРАМАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423982, Р.Т. Муслюмовский район, с.Старые Карамалы, ул.Кооперативная 115а,*
*Skarm.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-54-25*
ИНН 1629003858, КПП 162901001, ОГРН 1061687001144, ОКАТО 92242870001.

*Иске Карамалы авылы* *« 20 » 02 2019 ел*

**Карар № 6**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Җирләү һәм күмү эше турында"гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Җирләү һәм күмү эше турында"гы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында" гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Карарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең " 2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" гы 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1нче һәм 2нче кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә расларга һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Иске Карамалы авыл җирлеге һәм авыл җирлеге мәгълүмат стендларында һәм Иске Карамалы авыл җирлеге битендә Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында законда билгеләнгән срок түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/starokaramali.htm.

3. Карар үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Иске Карамалы авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе Л. М. Хәлиуллина

Мөслим муниципаль районы
Иске Карамалы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
« 20 » февраль 2019 ел № 6
карарына 1 нче кушымта

2019 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3200,38 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,76 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,33 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Иске Карамалы авыл җирлеге

башкарма комитет җитәкчесе Л. М. Хәлиуллина

Мөслим муниципаль районы
Иске Карамалы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
« 20 » февраль 2019 ел № 6
карарына 2 нче кушымта

2019 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районында
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү
бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтүнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 338,05 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 2862,35 |
| 3. Мәетне каберлеккә китерү | 873,75 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм гүргә иңдерү) | 1872,32 |
| Барлыгы | 5946,47 |

Иске Карамалы авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе Л. М. Хәлиуллина